# ҖИҢҮ КӨНЕ БЕЛӘН, ИПТӘШЛӘР!


СӨЙ ГОМЕРНЕ, СӨЙ ХАЛЫКНЫ, СӨЙ ХАЛЫКНЫҢ ДӨНЬЯСЫН!

# ДУСЛЫК

ОКТЯБРЬ РАЙОНЫНЫҢ ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГАЗЕТАСЫ.
ОБЩЕСТВЕННО-ПОЛИТИЧЕСКАЯ ГАЗЕТА ОКТЯБРЬСКОГО РАЙОНА.

Газета 1931 елның 9 июленнән бирле чыга. | №52 (7225) | 9 май, 1991 ел. ПӘНҖЕШӘМБЕ | Бәясе 4 тиен.


### ЧӘЧҮ ТӘМАМЛАНДЫ

«Яшь көч» колхозыннан шатлыклы хәбәр алынды. Мөстәкыйль хуҗалык булып әле беренче елын гына эшләвенә карамастан, ул беренчеләрдән булып бөртекле культуралар чәчүне тәмамлады. Игенчеләр бу җаваплы эшнең Җиңү бәйрәменә төгәлләнүенә икеләтә сөенделәр.

Бары тик аларның тырыш хезмәте аркасында гына колхоз мондый уңышка ирешә алды. Ике тракторчы Җ. Җамалов, Т. Вафин, чәчүчеләр И. Мингалимов, Ф. Вәлиәхмәтов, И. Шәйхиев, И. Вәлиев, С. Сидеряков, И. Әхмәтҗанов һәм башка игенчеләр турында бары җылы сүзләр генә әйтергә мөмкин. Чәчү чорында аларның һәркайсы планнарын 150—160 процентка үтәп килделәр.

# Кайнар котлау

Бөек Ватан сугышының утлы еллары бездән ерагайса да, аның даны бүген дә тоныкланмый әле.

46 ел элек шундый ук якты май көнендә соңгы туп тавышлары тынды. Салют утлары күкне яктыртты, миллионлаган йөзләрдәге шатлыклы елмаю бу көнне бизәде. Җиңү шулай килде. 1945 елның 9 мае тарихта мәңгегә җиңү көне булып теркәлде.

Мәңгегә—димәк, ул көннәрнең героик вакыйгалары еллар үтсә дә онытылмый, халык күңелендә мәңге яшәячәк.

Сез үз җилкәләрегездә сугыш авырлыгын күтәрдегез, кырыс фронт юллары буйлап үттегез, гаҗәеп киеренкелек һәм фидакарьлек белән халкыбызның, илебезнең азатлыгын һәм бәйсезлеген сакладыгыз. Бөек Җиңүгә юл авыр һәм озак булды, аның һәр елы илебез тарихына утлы юллар белән язылды. Әмма авыр сынаулар сезне сындырмады. Аяусыз көрәшләр, ут һәм ялкын аша сез үз халкыгызга тугрылык сакладыгыз. Фашизмга каршы авыр көрәштә илебез азатлыгын саклаган ветераннарга без тормышыбыз белән бурычлы. Без горур рәвештә сезне ҖИҢҮЧЕЛӘР дип атыйбыз. Сезнең каһарманлыкны бернинди үлчәү белән бәяләү мөмкин түгел.

Иң гаҗәбе—еллар сезнең чәчләрегезгә бәс, йөзләрегезгә җыерчык салса да күңелегезне картайтмаган. Гаҗәеп активлык, тормышны сөю сезне яшьләр арасына тарта, аларга данлы еллар мисалында патриотик тәрбия бирергә этәрә.

Бәйрәм белән котлап, без сезнең батырлыгыгыз, бүгенге көнгәчә саклый алган рухи күтәренкелегегез, күңел киңлегегез алдында баш иябез. Чын күңелдән сезгә, хөрмәтле ветераннар, нык сәламәтлек, зур шатлыклар телибез. Еллар җиле сезне картайтмасын. Сезгә яңа уңышлар, эшегездә иҗат куанычлары насыйп итсен. Озын һәм бәхетле гомер сезгә!

ХАЛЫК ДЕПУТАТЛАРЫНЫҢ ОКТЯБРЬ РАЙОН СОВЕТЫ.
КПССНЫҢ РАЙОН КОМИТЕТЫ.

---

1941 елның көзендә Норлатта 51 нче аерым укчы бригада төзелә. Бригаданы оештыруда, бигрәк тә материаль-техник тәэмин итүдә Норлат халкы зур булышлык күрсәтә. Менә быел 7 майдан 11 енә кадәр Норлатта 51 нче аерым укчы бригада һәм 54 нче гвардия укчы дивизиясенең элеккеге сугышчылары, бригада төзелүнең 50, Бөек Җиңүнең 46 еллыгы хөрмәтенә очрашуда булалар.


54 нче гвардия укчы дивизиясенең ветераннар советы Норлат шәһәре хезмәт ияләре, бригада һәм дивизиянең элеккеге сугышчылары сезне Җиңү көне белән кайнар котлый һәм сезгә нык сәламәтлек, күп елларга бәхетле тормыш тели. Татарстанның Октябрь районы һәм Норлат шәһәре җитәкчеләренә очрашуны оештыру һәм үткәрүдә зур булышлык итүләре өчен олы рәхмәтебезне җиткерәбез.

Район һәм шәһәр хезмәт ияләре! Сезгә кунакчыллык күрсәтүегез өчен солдат-ветераннарның зур рәхмәте.

СУГЫШЧАН ИПТӘШЛӘР КУШУЫ БУЕНЧА 54 НЧЕ ГВАРДИЯ УКЧЫ ДИВИЗИЯНЕҢ ВЕТЕРАННАР СОВЕТЫ ПРЕДСЕДАТЕЛЕ
С. ХИВРЕНКО.

# Сагынып килдек җиңү юлларыннан бергә үткән солдат дусларны...

## Гомер буе көтеп алган очрашу



Рәсемдә: И. А. Финогеев һәм П. Г. Кариков. Алар турындагы язманы сез газетаның 3 нче битеннән укыгыз.

## «ЙӨЗЕБЕЗ АК БЕЗНЕҢ...»

**51 нче укчы бригада ветераннары мәскәүле Александр Павлович Андрианов, Николай Дмитриевич Андрющенко (УССР, Макеевка шәһәре), Слуцкидан килгән Дмитрий Семенович Руденко машиналар төзү заводы коллективы белән очраштылар.**

Бер яклап дивизия оешкан көннәрнең ерак хатирәләрен уртаклашсалар, икенчедән кунаклар шушы еллар эчендә Норлатның кечкенә генә бер поселоктан үсеп килүче шәһәргә әверелүен шатланып расладылар. «Әле 10 ел элек очрашуга җыелганда гына да Норлат бу кадәр үсәр дип күз алдына китермәгән идек,—ди Александр Павлович.—Әмма ул чакта ук инде без Синдряков исемендәге колхозда булган очрашудан таң калып кайттык. Ул вакыттагы колхоз рәисе Н. Л. Филипповның үз колхозчылары өчен төзеткән профилакторийда медицина җиһазларының гаҗәп бай булуы сокландырды безне. Мин сезгә ант итеп әйтәм, моннан ун ел элек сезнең гади колхоз авылында күрергә туры килгән бу җиһазларны әле бүген дә Мәскәүнең фәнни-тикшеренү институтларында һәм клиникаларында гына күрергә мөмкин. Бай яшисез, матур яшисез!»—диде ул. Николай Дмитриевич белән Дмитрий Семенович та аның сүзен куәтләделәр.

Кунаклар һәм хуҗалар арасында эчкерсез әңгәмә шактый дәвам итте. Коллективның уңышлары, хуҗалык итү рәвеше дә кунаклар игътибарыннан читтә калмады. Бер-берсенә сораулар бирделәр, янә сугыш истәлекләрен кузгаттылар һәм янә дә бүгенге көнгә әйләнеп кайттылар. Очрашуда ерактан килгән кунакларга һәм коллективның үз ветераннарына истәлекле бүләкләр тапшырылды, якынлашып килгән бәйрәм белән котлаулар, матур теләкләр тынып тормады. Шулар арасында ветераннарның җан авазы да яңгырамый кала алмады: «Сугышка киткәндә миңа тулар-тулмас 18 яшь иде,—диде Александр Павлович.—Күпчелегебез шундый булгандыр. Без үзебезнең бурычны үтәдек. Йөзебез ак безнең. Бусы да хак. Соңгы елларда ветераннарга мөнәсәбәт төрлеләнә төште. Гаделсезлек, тупаслык очраклары да күренгәли. Шуны гына әйтәсем килә: без елдан-ел кими барабыз. Шәфкатьлерәк булыгыз. Тормышның башка юнәлеш алып китүенә ветераннар гаепле түгел бит...

Кичәдә ветераннар белән беррәттән әфганлы Сергей Мингалимовка да истәлекле бүләк тапшырылды. Сергейның уңайсызлана төшеп: «Бу бит Бөек Ватан сугышы ветераннары бәйрәме. Алар моны югалтулар бәрабәренә яулаганнар. Ә мин»,—дигән сүзләренә җавап итеп кунаклар болай диделәр: «Безнең сафлар көне-сәгате белән сирәгәя бара. Шуңа күрә без әфганлы егетләребез сугыш ветераннарына тиеш булган хокукларны бирергә бурычлыбыз. Өлкән ветераннарның васыяте шундый».

К. ҖАМАЛЕТДИНОВА.

## Алар батыр булдылар

### (51 нче аерым укчы бригада үткән юл)

Мәскәү өчен һәм Көнбатыш фронт өчен сугышлардан соң бригада Канязин шәһәренә күчерелә һәм анда 119 нчы укчы дивизия итеп формалаштырыла.

Волгоград сугышында катнашып, ул нык ныгытылган Суровикино шәһәрен азат итә. Моның өчен дивизия 54 нче гвардия укчы дивизиясе итеп үзгәртелә. Сугышта аеруча танылган солдатларга «Суровикино шәһәренең мактаулы гражданы» дигән исем бирелә.

Сугышчылар Миус елгасында оборонаны өзеп, дошманның кискен каршылыгын җиңеп Макеевка шәһәрен азат итәләр. Шуннан соң дивизиягә Югары Башкомандующий приказы белән «Макеевская» дигән исем бирелә.


Никопольск плацдармын юк итүдәге сугышчан хәрәкәтләрдәге уңышлары өчен аңа Кызыл Байрак, ә Николаев шәһәрен азат иткән өчен II дәрәҗә Суворов ордены тапшырылды. Сугышчан юлын дәвам иттереп, дивизия Днепрны кичте, Гомель районында оборонаны өзде, Минск шәһәрен азат итүдә катнашты һәм болар өчен Ленин орденына лаек булды. Аннан соң дивизиянең юлы Германиядә дәвам итте. Шталлупенен районында оборонаны өзде. Көнчыгыш Пруссиядәге сугышлардагы уңышлары өчен дивизия II дәрәҗә Кутузов орденын алды. Аннан соң Кенигсберг, Познань, Берлин, Прага өчен көрәш.

Дошманны үз өнендә тар-мар итү буенча заданиене намус белән үтәп, дивизия Ватанга кайтты һәм үзенең данлы сугышчан юлын тәмамлады.


Бүгенге санда

ХӨРМӘТ СЕЗГӘ, ВЕТЕРАННАР.
ХӘТЕР САКЛЫЙ.
ОЧРАШУЛАР, КҮРЕШҮЛӘР.
ОНЫТЫЛМАС МИЗГЕЛЛӘР.

# Җиңү көнен җиргә яулап биргән



Мәскәү. Кремль стенасы буенда билгесез солдат каберендәге мәңгелек ут.

## Элемтәче Зоя

Олыгаеп та баралар инде безнең Ватан иминлеген саклап калган ветераннар: зур авырлыклар, күп югалтулар бәрабәренә яулап алынган Җиңү көненнән соң инде 46 ел узып бара.

Зоя Прокопьевна Тихонова да сиксәненче дистәне ваклый башлады. Сәламәтлеге начар булуга карамастан, ул еллар агымына бирешергә теләми әле—күңеле көр, җаны кешеләр өчен һәрвакыт ачык аның.

Илебезгә дәһшәтле кара яу бәреп кергән вакытта 20 яшьлек телеграфист кызның Норлат элемтә узелында эшли генә башлаган чагы була. Әмма тормыш язы булган яшьлеген дә, киләчәккә якты уй-хыялларын да сугыш челпәрәмә китерә.

Беренчеләр рәтендә аны да, һөнәрен исәпкә алып, хәрби хезмәткә чакыралар. Казанда алар бөтен республика буенча 360 элемтәче кыз җыелалар һәм төрле фронтларга озатылалар.

Хәрби антын элемтәче Зоя Полтава шәһәрендә кабул итә, ә аннары сугыш өермәсе аны үз упкынына алып кереп китә...

Әле кайчан гына әнисенең җылы кочагында ваемсыз гына яшәп яткан кыз балага саллы ир-егетләр өчен дә зур сынау булган бу дәһшәтле көннәрнең бөтен авырлыгын үз җилкәсендә татырга туры килә.

Яу кырыннан үзенең иптәшләренең үле гәүдәләрен алып чыккандагы кичерешләрне, ялгызы постта торган вакыттагы халәтне,озын походлар үтү, бозлы елгалар кичү, урман кисеп землянкалар төзү авырлыкларын һәм солдат башына төшкән барлык хәлләрне ничек санап, нинди сүзләр белән сөйләп бетермәк кирәк!

—Менә ничәмә дистә еллар үтүгә дә карамастан, ул вакыйгаларны искә төшерә башласам, минем йөрәгем кузгала, үзебез исәнимин кайтсак та, безнең рухи җаныбыз гарипләнеп кайтты,—ди үзе һәм сугышта булган хатын-кызлар турында Зоя Прокопьевна.

Ә шатлыклы Җиңү язын ул Венгрия башкаласы Будапештта зенит артиллериясе наводчигы булып каршы ала.

Яшьлектә сайлаган һәм хәтта сугышта—өстенә чын мәгънәсендә ут явып торганда да аерылгысыз юлдашы булган элемтәче һөнәрен, Зоя Прокопьевна кайтуга тагын дәвам итә.

Кеше шатлыклары, кайгы-кичерешләре һәм башка бөтен яңалыклар беренче булып телеграфчылар кулыннан үтүе дә бәлки аны гомере буе җаваплы да, зур түземлелек сорый торган бу һөнәргә тугры булып калырга этәргәндер. Аның хезмәте өчен иң кирәкле булган төгәллек, игътибарлылык сугыш кырында кешеләр язмышын хәл итүче төп сыйфат булса, ул тыныч тормышта да үзенең мәгънәсен югалтмый, чөнки һәркайсыбызның шатлыгы, кичектергесез хәбәре Зоя Прокопьевна кулыннан үтә.

II дәрәҗә Ватан сугышы ордены һәм күпсанлы медальләр белән бүләкләнгән сугыш һәм хезмәт ветеранын бүгенге көндә дә коллективта үз кеше итеп күрәләр, бәйрәмнәрдә ул—көтеп алынган кадерле кунак. Башка көннәрдә дә хезмәттәшләре аның көндәлек мәшәкатьләре, ихтыяҗлары белән даими кызыксынып торалар, кулларыннан килгән кадәр ярдәм итәләр.

—Сугыштан исән кайта алуым һәм тыныч тормышта хезмәт итеп һәм хезмәттәшләремнең һаман да ихтирамын тоеп яшәвем белән мин бик бәхетле,—ди Зоя Прокопьевна.

Ә май—Җиңү көнендә ул бу бәхетне тагы да ачыграк тоя. Без аның яшьләрчә ялтыраган күзләрен, шатлыклы якты йөзен күреп шуңа һичшиксез шатландык.

Р. ШӘЙХУЛЛИНА.

## Норлаттан киттеләр, Берлинга җиттеләр

Дәһшәтле 1941 елда, немец-фашист басып алучылары Ватаныбыз башкаласы Мәскәүгә омтылган көннәрдә Дәүләт Оборона Комитеты карары белән сугыш хәрәкәтләре алып бару өчен Норлатта төзелде 51 нче укчы бригада.

Бригада частьләрен оештыруда кыенлыклар аз булмады. Ләкин партия һәм Совет органнарының материаль һәм мораль ярдәмнәре белән 51 нче укчы бригада билгеләнгән срокка формалашты.

Хезмәт ияләре фронтка озату митингында сугышчыларга немец-фашист басып алучыларны илебездән куып чыгаруда һәм фашизмны үз оясында тар-мар итүдә кыю һәм батыр көрәшүләрен теләгән наказлар бирделәр.

1941 елның декабрендә бригада Ватаныбыз башкаласы Мәскәүне саклауда иң актив көрәшә. Мәскәү оборонасындагы сугышта күрсәткән батырлыклары өчен бригаданың барлык составы «Мәскәү оборонасы өчен» медале белән бүләкләнде.

Гитлерның сайлап алынган армиясе Мәскәү янында тар-мар ителгәннән, куркыныч беткәннән соң ВГК ставкасы карары буенча 51 нче бригада Төньяк-Көнбатышка, ә аннары Калинин фронтына күчерелде. Алар анда да 4 нче удар армия составында һөҗүм итү сугышларында актив катнаштылар.

1942 елның апрелендә 51 нче аерым укчы бригада базасында 119 укчы дивизия сугышчылары Сталинград фронтында Суровикино шәһәрен азат итү өчен барган сугышларда үзләрен аеруча күрсәтәләр һәм 54 нче гвардия дивизиясе итеп үзгәртелә.

51 нче аерым укчы, соңыннан 119 укчы дивизия, 54 нче гвардия укчы дивизиясе Сталинградтан Берлинга һәм Прагага кадәр данлы сугышчан юл үтте. Составның 99 проценты сугышта күрсәткән батырлыклары өчен хөкүмәт бүләкләренә лаек булдылар, ә дивизия Ленин, Сугышчан Кызыл байрак, Суворов, Кутузов орденнары белән бүләкләнде. КПССка һәм халыкка бирелгәнлек, сугышчан осталык, Ватанга чиксез мәхәббәт, дошманга булган нәфрәт безнең сугышчыларны немец-фашист басып алучылары өстеннән җиңүгә китерде.

Бүген, 50 ел узгач, дивизия ветераннары шәһәр һәм район хезмәт ияләре белән очрашалар.

Бу тантаналы көндә без сезне сөенеп тәбриклибез һәм батырлык, кыюлык күрсәткәнегез өчен чын йөрәктән рәхмәт әйтәбез.

### ДНЕПРНЫ КИЧҮ

Немец-фашистлардан хутор һәм авылларны азат итеп, гвардия капитаны Кисенков подразделениесе сугышчылары дошманга һөҗүм итеп Днепр ярына чыктылар. Биредә, яр буенда ук, тагын бер эре торак пунктны дошманнардан азат иттеләр. Елганың икенче ягында дошман совет сугышчылары һөҗүмен тоткарлау өчен шашынып ныгытмалар корды.

Җиргә томанлы төн житте. Вакыт-вакыт немец ракеталары безнең як ярны яктырталар. Ул чакта бирегә күп кеше шөгыльләнүен белергә була иде. Ә алар су читенә бүрәнәләр китерәләр, тимер мичкәләр, агач капкалар, такталар төшерәләр, аларга пулеметлар, минометлар, танкка каршы кораллар урнаштыралар.

Бер төркем сугышчыларның фашистлар җимереп ташлап киткән көймәне сөйрәп килүләре шәүлә булып суга төшә. Алар сүс, дилбегә кисәкләре белән көймәнең ярыкларын ямыйлар, берәздән ул суда чайкала башлый инде. Ильченков саперлары бүрәнәләрдән зур рамга охшаган нәрсә әмәлләгәннәр.

Биредә, үз солдатлары янында командирлар, партия-политик һәм комсомол работниклары—гвардия капитаны Муравенко, өлкән лейтенант Варфоломеев, комсомол-оештыручы лейтенант Боровик. Әнә бер төркем сугышчылар. Иптәш Муравенко алар белән сөйләшә.

—Бу урында,—ди ул гвардиячеләргә,—моннан 3 йөз ел элек Украинаның бөек гетманы Богдан Хмельницкий үзенең полкын поляк паннары белән азатлык көрәшенә туплаган. Шушы тарихи урында азатлык сөюче Запорожье казаклары Украина халкын коллыкка төшерергә теләүче дошманны бөтенләй тар-мар иткәннәр. Без—данлы Богдан токымы. Гитлерчыларны Украинаның сул ягыннан куып чыгарыйк, уң ягын да бәхетле итик.

Кайдандыр, күктәге болытлар арасыннан тонык ай чыга. Елганы кичәргә вакыт. Сигнал. Һәм беренче группа сугышчылар оешкан төстә, елга читенә киләләр. Мылтык, котелок, көрәк чыңлаган тавыш та юк. Саллар инде суда чайкала һәм аларга зур тизлек белән солдатлар урнаша.

—Әнә ул минем Днепрымның озак көттергән уң як яры,—ди беренче салдагы Чернигов егете Орел. Һәм күзләрен Көнбатышка текәп әлеге минутларны ничек көтүе, борчылуы турында шыпырт кына иптәшләренә сөйли.—Минем гаиләм әле бүген дә гитлерчылар кулында, теге як ярда. Мин үземнең сәгатемне көтеп алдым, аларны явыз дошманнан азат итәргә барам.

Шушы мизгелдә якында гына, су өстендә бер-бер артлы миналар шартлый. Гитлерчылар хәвефне сизеп елганы кичүчеләргә каршы каты һөҗүм башлыйлар. Әмма соңлаганнар. Гвардиячеләр салларга урнаштырылган пулеметлардан җавап уты ачтылар. Кисенков солдатлары икенче як ярга тиз чыгалар. Беренчеләрдән булып уңъяк ярга Украина җиренә өлкән лейтенант Дороненко сугышчылары, алар артыннан офицер Сержанов егетләре чыкты. Алар тиз-тиз генә оборона алалар, үзләренең утлары белән кичүче подразделениеләрне ышыклыйлар.

Берничә минут вакыт уза. Капитан Кисенковның барлык гвардиячеләре дә елганы кичәләр, позиция алалар һәм һәр минутта һөҗүм башларга әзер торалар. Ләкин гвардиячеләр Днепрны оборона яулау өчен генә кичмәделәр. Сугышчылар әле урнашалар гына, ә инде капитан Кисенков разведка җибәрә. Разведчиклар таң алдыннан китәләр, ә сул як ярга: «Днепр уңышлы кичелде, сугышчан задание үтәүне дәвам иттерәм»,—дигән радиограмма җибәрелә.

И. САНДЛЕР.

Элекке председательләр корпусы. Бу рәсемгә күз салган газета укучы күңеленә нәкъ шундый фикер килүе бик ихтимал. Һәм чынлап та биредәге иптәшләрнең күпчелеге теге яки бу хуҗалыкка җитәкчелек итте. Х. К. Кәлимуллин (уңнан беренче) Ульянов исемендәге колхозда озак еллар рәис хезмәтен башкарды. С. С. Гафуров, П. И. Ильин да (уңнан өченче һәм дүртенче) 30 ар ел гомерләрен шундый җаваплы хезмәткә багышлаганнар. Фронтта алган чыдамлык, ныклык, принципиальлек Н. М. Смирновка партиянең район комитетында озак еллар эшләргә җитәрлек энергия бирде.



Хәер, мондый сыйфатлар М. Х. Рәҗәпов, Н. И. Маслаков, А. Д. Дмитриевка да хас. Алар да төрле елларда, төрле хуҗалыкларда рәис хезмәтен башкардылар. Йөкләтелгән башка поручениеләрне дә хәрбиләрчә башкардылар партия солдатлары. Әлбәттә,бүген бигрәк тә,аларның бу хезмәтенә скептикларча караучылар табылыр,ләкин бер нәрсә хакыйкать:үзенә йөкләтелгән участоктагы хезмәткә бар энергияләрен биреп эшләделәр алар.

Бу рәсемдә тагын ике ветеран бар. Сулдан беренче һәм уңнан икенче булып баскан иптәшләрне бәлки газета укучылар танырлар дип ышанып калабыз.

# Халкыбызның даны мәңгелек

## 1. 51нче укчыдан

Аларны Норлат тагы үзенә җыя. Нәкъ 10 ел элек биредә үткән очрашу җылысы якты истәлек булып әле дә күңелдә яши. Норлат урамнары, аның бәйрәм тирәсендә аерынкы бизәлеш ала торган үзәк мәйданы кунакларга үзенчә якын. Кунакханәнең җыйнак бүлмәсендә өстәл артына җыелган ветераннар —51 нче аерым укчы бригада сугышчылары җай гына шул чакта гәп алып баралар.

Аһ, ул истәлекләр! Сугыш ерагайган саен, аның аша үткән кешеләр арасы якыная, дуслык ныгый, хатирәләр кадере арта төшә. Бүген Норлатка полкташлар очрашуына иң беренчеләрдән булып килгән Н. П. Снежкин, Д. С. Руденко, А. П. Андрианов, В. П. Колотыгин шул хакта сөйлиләр. Аларның күбесе Норлатта икенче кат, 10 ел эчендә шәһәрдә булган үзгәрешләргә сокланалар да, шатланалар да. Ә медицина службасы полковнигы, элекке рота командиры Николай Павлович Снежкинның моннан 50 ел, аннан да элегрәк чорны да искә алу мөмкинлеге бар. Мәскәү өлкәсенең Красногорск шәһәреннән килгән бу ветеранны Норлат белән күп нәрсә бәйли. Шулай туры килгән: Казанда укыган, Чулпан участок больницасында практика узган, Норлатта туганнары яшәгән һәм биредә формалашкан бригада составында яу кырына озатылган ул. Норлатның тәбәнәк бараклары, аякны каерып алмаслык балчыгы белән янәшә онытылмас врач К. И. Березина турында, үзләрен елап сугышка озаткан норлатлылар турында якты истәлекләр яши аның күңелендә. Гомере буе татар халкы белән янәшә, аралашып яшәгән, аларга чиксез хөрмәт белән караган ветеранның сүз сөрешендә бүгенге көнебез, яшәешебез турында олы фәлсәфи акыл тоясың.

Зирәклек, акыл, сабырлык, шул ук вакытта сокландыргыч активлык алар белән аралашуда күзгә ташлана. Батарея командиры, өлкән лейтенант Александр Павлович Андрианов бригадага Мәскәүдә оешкан чаңгычылар батальоныннан калган 12 сугышчы белән бергә кушыла. Ул да Норлатта икенче тапкыр, дуслары, танышлары бихисап. Шәһәрнең 3 нче мәктәбендә узган юлы очрашкан 2 класс укучылары— бүген чыгарылыш класс егет-кызларын күрәсе килә, ветераннар аллеясында үзе утырткан агачка да һичшиксез күз саласы бар, 547 нче ПМК коллективы, ветеран хәрәкәте активистлары турында да җылы хисләр саклый ул. Шундый һәр очрашуны яшьләргә хәрби-патриотик тәрбия бирүдә файдаланырга тырыша.

Әңгәмә җай гына ага тора. Себердә туган, хәзер Днепропетровскида яшәүче Вениамин Петрович Колотыгин сугыш елларына кагылышлы һәр истәлекне дулкынланмыйча искә ала алмый. Ул—Бийск шәһәрендә формалашкан чаңгы батальоны вәкиле. Хәрби көрәш юлы аны да әлеге бригадага китереп кушкан. Ә күпмесе яу кырында ятып калган! Нинди лачыннар башларын салганнар! Хәзерге тыныч шартлардагы милли бәрелешләр турында сүз чыккан саен шул егетләрнең рәнҗүен тойгандай була: ә без милләт аерымлыгын исәпләмәдекме соң? Дмитрий Семенович Руденко да шулай ди. Үз теләге белән фронтка киткән, көрәш барышында бригадага кушылган ветеран Норлатны беренче тапкыр күрә: ошаган, ә алда әле 2—3 көн кичерешләр, тәэсирләр тулы очрашулар, очрашулар.

Хәер, нигә—алда? Очрашулар инде бүген башланды. Кинәт бүлмә ишеге ачылды да аннан шат чырайлы, мәһабәт гәүдәле солдат килеп керде. Дан орденнарының тулы кавалеры разведчик Порфирий Герасимович Кариков икән.

—Гаҗәеп куркусыз, чын герой иде,—диеп таныштырдылар аны өстәл янындагылар. Дулкынлануы йөзенә чыккан Порфирий Герасимович тизрәк китәргә ашыкты. Ул 46 ел очрашмаган,күптән үлгәнгә саналган дустын эзли. Ике ветеран, ике солдатның очрашу мизгелен язасы килә. Әмма бусы соңрак, бусы—аерым сөйләшү.

Күпме булачак әле андый дулкынландыргыч минутлар!

Норлат ветераннарны җыя. Аларның орден-медальләре чыңлавы, вәкарьле адымнары, уйландырырлык хикәятләре, киңәшләре бу көннәрне шәһәр тормышына үзенчәлекле төсләр өстәячәк.

Бәйрәм белән сезне, кадерле кунаклар! Норлат җиренә рәхим итегез, төкле аягыгыз белән!



Самат Гаязович Гафиятуллин, III дәрәҗә Дан һәм II дәрәҗә Ватан сугышы орденнары кавалеры, гомерен яшь буынны тәрбияләүгә багышлады. Үзе сугышта күп кан койганга бәлага юлыккан кешеләргә һәрчак ярдәм кулын сузарга әзер тора ул. Самат Гаязович актив донор да, аның каны күп тапкырлар җәрәхәт алган кешеләрнең гомерен саклап калуда булыша.

## 2. Гомер буе көткән очрашу

Инде чәчләре агарган, йөзләренә еллар эзе булып җыерчыклар иңгән ике ир-ат бер-берсенә текәлгәннәр дә тавышсыз гына елыйлар.

—Синме бу, Иван?

—Мин, Порфирий, мин. Исән-имин килеш мин.

Аһ, Иван, Иван! Кая китте синең төз гәүдәң, лачындай кыю карашың? Соңгы күрешү көнне дә шундый булып хәтердә калган идең син. Жлобино шәһәреннән көньяктарак алар, разведчиклар иртүк солдатларны атакага күтәрделәр. Кинәт траншеяның өченче линиясендә гитлерчылар дзоты күренде. Иван Финогеев яшен тизлегендә дзотны танкка каршы граната белән бастырды. Әмма шулчак бер фриц аның күкрәгенә төбәп атып җибәрде. Чалгы белән чапкандай җиргә егылды.Иванны госпитальгә озатканда ир-егетләр тешләрен кысып яшьләрен тыйдылар.

—Хуш, Иван, бәлки күрешербез әле,—дигән иде Порфирий да. Әмма соңгысына щикләнде: исән калырмы? Ай-һай бит ярасы!

Сугыш еллары разведчик Порфирий Герасимовичны күп талкыды. Өч дәрәҗә Дан ордены кавалеры,дошманның 26 «тел»ен тоткан кыю разведчик турында ул елларда легендалар йөрде. Язмышы бәхетле булды: сугышны исән-имин тәмамлады, аннан соң бронетанк академиясен укып бетерде. Күрше Чувашстанның Батыр районы, Сугут авылы егете, хәрби һөнәр үзләштереп, сугыштан соң 15 тору урынын алыштырды, күп илләрдә булды, яшәде, чын дуслар тапты һәм бернәрсәне ахырынача төшенде: истәлекләрнең иң күңелгә уелганы— сугышчан хатирәләр, дусларның иң кадерле, тугрылары — фронтташ дуслар. Ростов на Дону ягында озын буйлы, киң җилкәле Иван Финогеев күз алдыннан китмәде. Исәнме ул, кайда яши? Сорау белән төрле якларга хатлар очты, «Красная Звезда» газетасы һәм башка басмаларда чыккан язмаларда да гел шул сорауны куйды. Әмма нәтиҗәсез.Ьәм ниһаять,узган ел Подольск шәһәрендәге үзәк музейдагы архивны актарганда үзе эзләгән фамилиягә юлыкты: Иван Александрович Финогеев Ростов на Дону өлкәсенә тиз арада хат җибәрелде. Калганын Порфирий Герасимовичның хатыны Надежда Павловна сөйли.

—2 ай көттек җавап, 3 ай—юк. Көннәрдән бер көнне почтальон хат бирә, кире адресы—И. Финогеев. Порфирий дим, син Иваннан хат көтәсеңме? Көтми буламы инде, үзем күреп торам бит. Бер юлны укый да елый, икенчесен укый да көлә, фотосын кулына алып үбә.

Әнә ул хат: «Без бит синең белән бер ипи катысын икегә бүлеп ашадык, ничә тапкыр үлем белән йөзгә-йөз очраштык. Мин сугышта 8 тапкыр яраландым, 3 тапкыр контузия алдым, ә шулай да исән-сау яшибез. Бу түгелме бәхет?» Һәм шунда ук— ул риза булса очрашу, күрешү турында тәкъдим. Әлбәттә, риза, әлбәттә күрешергә. Һәм шунда, нәкъ вакытын белеп дигәндәй, Норлатта укчы бригада очрашуы турында чакыру килеп төшә П.Г. Кариковка. Ә ул аны Иван Александровичка юллый, һәм килешәләр: аларны күрештерергә тиешле урын нәкъ Норлат булырга тиеш.. Одессадан Кариковлар гаиләсе, Казахстаннан, (ул сугыштан соң шунда яши) Соколовский районының Налобино авылыннан Финогеев зур өметләр, очрашу теләп кечкенә Норлатка ашыгалар.

—Иван, исәндәме?..

Порфирий, хәтерлисеңме?..

Әлбәттә, хәтерлиләр! 17—18 яшьлек, әле балалыклары да чыгып бетмәгән егетләр малайларча башкисәрлек, өлкәннәрчә инанганлык, куркусызлык белән сугыш дигән мәкерле уенда нинди генә каршылыклар кичмәделәр дә, нинди генә хәлләргә юлыкмадылар?! Петя—Порфирий Герасимовичны ул чакта шулай дип йөртәләр иде, Ваня, ярый исән-имин әйләнеп кайттылар, ә нинди асыл егетләр яу кырында башларын салдылар, күпмесе хәбәрсез югалды. Ветераннар истәлекләре саен уртак дусларын юксыналар. Ә бәлки аларның кайберләре исәндер? Эзлисе, эзләнәсе күп әле. Менә бит—насыйп булгач, 46 елдан соң да очраштылар. Туганнардай якынлык, бергә гомер кичергән иптәшеңдәй аңлашу һәм кош откандай шатлану аларның һәр икесен дә бераз теге еллардагыдай малайлаткан, йөзләрдәге җыерчыкларны да язган. Надежда Павловна Карикова, карт солдатның тугры тормыш иптәше, ветеран хәрәкәтендә актив катнашучыларның берсе аларга караган да күз читендәге яшен сөртә. Кулында—блокноты, анда—үзе багышлама итеп язган шигыре:

«Мин бу очрашуны гомер  
буе эзләдем..  
диелгән юллар бар анда. Менә ул, гомер буе эзләгән очрашу.

**С. ХӘЙРУЛЛИНА.**

## Отряд ветераннарны җыя

54 нче укчы дивизия ветераннарын 1 нче мәктәп оркестр белән каршы алды. Якын танышларыдай очрашу, туганнардай җылы күрешү, кочаклашу.. Әйе, дәһшәтле сугыш утын, үлемне бергә күрүчеләр өчен генә түгел, әле яшь буын өчен дә гаҗәеп дулкынландыргыч тәэсир итә мондый очрашулар. Бигрәк тә җиңү көнендә ерак 45 нчегә килеп чыккандай хис итәсең үзеңне.

Районыбызга килгән кунак-ветераннар Норлат җирендә беренче очрашуларын нәкъ шул мәктәптә башладылар. Ни өчен 1 нче мәктәп? Моның сере бар, әлбәттә. Чакырып алынган кунакларның биредә очрашулары мәктәп хуҗалары өчен аерата истәлекле. Норлатта 51 нче аерым укчы дивизия оешуы 1979 нчы елда гына беленә. Сугыш ветераны И. Л. Сандлер җитәкчелегендә 1 нче мәктәп укучылары эзләнү отряды оештыралар һәм аны «Аталарның сугышчан даны варислары» (НБСО) дип атыйлар. Шуннан соң күп эш эшләнде, байтак ветераннар табылды, бригаданың сугышчан юлы өйрәнелде. Эзтабарлар бу эшләрен актлар залында эленгән «51 нче аерым укчы бригада» стендында күрсәткәннәр. Хәзер отрядта география укытучысы В.А. Гордеев җитәкчелегендә дүртенче буын эшли.

Мәктәп очрашуга бик җентекләп хәзерләнгән. Актлар залына пионерлар сәламләп озатты. Хәтта бәйрәмчә бизәлгән зал да ягымлы каршы алды. Очрашу башында ук отрядның байрагын каршы алу тантаналы минутларның берсе иде. Ветераннар һәм укытучылар биредә ун ел элек булган очрашуны искә төшерделәр.

Кунакларның адреслары бик еракка сибелгән: Мәскәү, Минск, Мокеевка, Полтавщина, Воронеж өлкәсе, Казан..Кемдер биредә өченче; икенче тапкыр, ә кайсыдыр беренче. Соңгылары өчен бу очрашу аеруча дулкынландыргыч иде.

Медицина хезмәте полковнигы Николай Павлович Снежкин Красногорскидан. Ул норлатлыларның эшелонны озатуларын җылы искә ала. 1941 нче елның көзендә озатучылар хатын-кызлардан гына торгандай була.

Александр Павлович Андрианов—Мәскәүдән. Ул зур горурлану белән НБСО җибәргән таныклыкны укыды. Ә анда ветеранның мәктәптәге сугышчан дан музеена мактаулы члены итеп кертелүе турында язылган. Бу аның өчен истәлекле документ. Мактаулы член бер ул гына түгел икән: С. С. Хивренко, А. П. Андрианов, Г. М. Орел исемнәрен укучылар иң өскә язып куйганнар иде.

Николай Иванович Кобзинь сугышны Прагада тәмамлый. 46 ел инде үзе өчен кадерле «Җиңү парадына чакыру» кәгазен саклый. Парадта катнашуын ул зур горурлык белән сөйли.

Очрашуның азагында кунаклар һәм мәктәпнең үз ветераннары укучылардан бүләккә китаплар һәм кып-кызыл лалә чәчәкләре кабул итеп алдылар.

**Ф. ГАЛИМОВА.**

# Җиңүләрне яулап алган көннәр онытылмаслар гомер-гомергә...

*Яңарган хатирәләр*

## Без полкташлар

Сугыш бер дә күңелдән китми. 21 июнь, 9 май көннәре якынлашканда күңелдә сугыш хатирәләре аеруча яңара.

1940 нчы елның февралендә фин сугышы бара иде. Мине хәрби хезмәткә алдылар, станциядә халык байтак иде, бер эшелон тулды. Кулга мылтык тотып карамаган кешеләрне шуннан ук сугышка алып китәрләрме икән, дип баш ватып бардык юл буе. Ә поезд Көнбатышка, Украинага таба озак барды. Ниһаять, Киев өлкәсенең Василькөво шәһәренә барып җиттек. Шунда 791 нче укчылар полкына, элемтә ротасына билгеләделәр.

1941 елның җәендә безне җәяүләп Бессарабиягә алып киттеләр. Әлегә сугыш юк, көзгә өйгә кайтырга дип өметләнеп тора идек. Әмма 1941 елның 22 июне барысын да челпәрәмә китерде. Өч көннән соң Көнбатыш Украинада беренче сугышны кабул иттек. Иртән бөтен күк йөзе каралып китте, каты шартлаулардан җир ыңгырашты. Фашист самолетлары өстебезгә ябырылып килде. Дошман көчле дә, сугыш тәҗрибәсе шактый туплаганы күренә иде. Ә безнең подразделениеләр аны хәзерлексез каршы алдылар. Шуңа да Көнчыгышка таба чигенергә мәҗбүр булдык.

Шул елның декабрендә без Мәскәү өлкәсе җирендә идек. Дошман ыргылып башкалабызга таба килә. Солдатлар талчыгудан, йокысызлыктан баскан җирдән карга авалар, шуңа карамастан, ныклы оборона төзи алдык. Калын итеп яуган кар һәм 40 градуска кадәр җиткән суык немецлар һөҗүмен Волокаламск янында туктатырга мәҗбүр итте. Ә безгә шул гына кирәк. Таң алдыннан безнең гаскәрләр һөҗүмгә юнәлде. Биш көн эчендә аларны Мәскәүдән 120 километрга кудык. Бу шатлыкны сөйләп тә, язып та аңлатырлык түгел.

Шул сугышларда безнең якташлар, армия хезмәтенә бергә китүче иптәшләрем һәлак булдылар. Алар В. Албутов, М. Глушкин, Е. Ф. Законов, А. В. Егоров һәм башкалар. Ә В. Иванов һәм М. Шамбин каты яраланып госпитальгә озатылдылар. Алар турында аерым сөйлисем килә. Василий Ивановны, ул Чуваш Мәҗесе авылыннан иде, сугыш башланганчы без, солдатларга үрнәк итеп куйдылар. Сугышчан һәм политик хәзерлек отличнигы иде. Сугышта командование аңа кече лейтенант званиесен бирергә булды. Шундый отличниклар ротабызда байтак иде. Мәсәлән, Биләр Озеро авылыннан Михаил Шамбин. Кызлар кебек чибәр, характеры белән искиткеч йомшак, ләкин нык, кыенлыкларга бирешмәс кеше иде. Михаил Максимович сугыштан исән-сау кайтты. Гаилә корды, гомер буе туган авылында укытучы булып эшләде, балаларны да үзе, сугышчан дуслары кебек нык ихтыярлы, батыр, түземле итеп тәрбияләргә тырышты.

Әйе, бу көнне полкташларны кабат күрәсе, хатирәләр белән бүлешәсе килә иде. Газета аша аларны бәйрәм белән котлыйм.

**Н. ВАСИЛЬЕВ.**
Норлат шәһәре.




### Кырык биштә кайтмый калган яшь атага

Син яшь ата булып яуга киттең,
Бер йомарлам улың калган иде.
Әнкәсенең куенында сабый,
Татлы йокысына талган иде.

Син яшь ата булып яуга кердең,
Туган туфрагыңда калды балаң.
Соңрак аңа хәбәр сөйләделәр:
«Әткәң герой булып үлеп калган...»

Синең буын әнә дәвам итә:
(Дошман шуны ничек аңламаган?!),
Чал чәчле ир бүген, үзе солдат
Синнән туып кына калган балаң...

Сиңа килгән бүген серләшергә
Синнән туып калган синең каның...
Ата һәм Ул җаны серләшкәндә
Чәчәк куя тып-тын оныкларың.

**К. ҖАМАЛЕТДИНОВА.**

## Таныш булыгыз: яңа автор

Түбән Норлат авылында туып үскән, бүгенге көндә Киекле килене Роза Мәслахова. Мәктәптә укыту өстенә, ул шигырьләр язарга да вакыт таба.

### СОЛДАТКА

Диңгездә, тайгада, чүлләрдә
Булсаң да син тауның үрендә;
Онытма син, солдат, һәрвакыт
Ананың йөрәге түрендә.
Көтәләр аналар сездән хат,
Зарыгып яшьләнә күзләре,
Йөрәге сыкранып торса да
Белгертми—түземле үзләре.
Сыйпый ул кадерләп киемеңне,
Ана гел улкаен сагына.
Кайткачтын, күреп син әнкәңне,
Шаккатма чәченең агына.
Тик еш яз—көттермә хатларың,
Ананы онытырга ярамый.
Аның бит әрнегән йөрәген,
Бары шул хатларың дәвалый.



Чәчәк тәлгәшләре—ак энҗедән,
Энҗеләре гаҗәп хуш исле...
Дөнья бүген шул сафлыктан тора,
Сизәсеңме шуны, и кеше!
Чәчәк тәлгәшләре бигрәк назлы,
Түгелергә торган күңел күк...
Шушы язның шушы изге мәле
Гомер кабатланмас көндер күк.
Тәлгәш-тәлгәш шомырт куаклары,
Туй күлмәге мәллә бу сезнең?...
Сугыш толларының күз яшеме,
Гомер сагышымы, үксезнең?...
Чәчәк тәлгәшләре купшы, назлы
Башкайларын түбән игәннәр...
Кул сузмагыз, зинһар, табигатьнең
Шул мизгелен изге дигәннәр...

**Н. Туганов фотоэтюды.**

## Ул үткән юллар

Районда танылган кешеләр бик күп. Без аларның Мактау такталарында, залларда, музей бүлмәләрендә рәсемнәре булганнарын гына беләбез. Ә янәшәбездә, арабызда Бөек Ватан сугышында җиңү көнен якынайту өчен канын кызганмыйча үзеннән тыйнак, әмма зур өлеш керткән гади солдат якташларыбыз бар. Командирларының һәр приказын карусыз үтәп килгән бу ветераннарның исеме мемориаль такталарда юк, үзләре дә көннән-көн сирәгәя баралар. Менә шундыйларның берсе—Фома авылында яшәүче Җәләлетдин ага Садретдинов.

—Без,—дип искә ала ул,—авылдашларым белән Кызыл Армиягә фин кампаниясеннән соң чакырылдык. Норлаттан чыккан эшелон белән Полтава шәһәренә килеп төштек, фин сугышында сирәкләнгән полкны тулыландыру өчен иде бу. Мин авылдашым Әхмәт Сагыйров белән пулеметчылар хәзерләү отрядына эләктем.

Аларга бергә аз хезмәт итәргә туры килә. Авыр яраланган Әхмәтне Новороссийск тирәсендә Рәхим Зарипов күрә. Батыр, кыю бу егетнең соңгы минутлары турында ул хәбәр алып кайта. Пулеметчы гына булырга туры килми аңа, артиллерист, телефонист та була. 45 һәм 76 миллиметр көпшәле артиллерия пушкалары немецларга каршы дәһшәтле корал санала ул чакта.

Гитлерчылар белән бергәбер очрашуны искә алуы бик авыр аңа. Чөнки солдат солдат инде, ул бит сугыш башламый, приказ үтәүче генә.

Немец солдатларын исерек һәм куркак, ә офицерларын үзләрен югары тотучы итеп яздылар һәм кинода күрсәттеләр, бу дөреслеккә туры киләме? дигән сорауга ул өздереп җавап бирде: «Билгеле аларда кораллану, туклану, кием-салым күпкә яхшы иде. Ләкин куркаклар дип әйтмәс идем. Солдат аларда да приказ үтәүче генә бит».

Аның хәтерендә Кызыл Йолдыз орденына лаек булган истәлекләр яңара. Кырым өчен барган сугышларның берсендә, йөзә белүчеләрне сайлап, караңгы төндә аларга телефон аппаратлары һәм сугыш кирәк-ярагы алып көймәдә Керчь бугазы аша күчәргә дигән бурыч куела. Зур саклык белән башта камышлыкка килеп чыгалар, аннары элемтәне көйләгәч яктыра башлау белән немецларның ут нокталары турында мәгълүматларны үзебезнекеләргә хәбәр итә башлыйлар.

—Күрәсең безнең бу хәбәр үз эшен эшләгәндер, барыбыз да хөкүмәт бүләкләре алдык, Кызыл Йолдыз ордены шул операция өчен бирелде,—ди Җәләлетдин ага.

Кырым азат ителгәч, аларны Брестка китерәләр. Польшаны азат итү башлана. Висла елгасын кичкән чагында исән калган тимер күпер күрсәткечендә «Берлинга—500 км» дигән язу күрә Җәләлетдин.

Әйе, Берлинга да җитә солдат, сугыш кырларында ике тапкыр яралана. 1945 елның көзендә аны демобилизациялиләр.

Җиңү шатлыгына исән калу, туганнары белән очрашу шатлыгы кушыла. Озак тормый солдат, авылның әйбәт кызы Зәйнелгарәпкә өйләнә, гадәти туй, гадәти тыныч тормыш башлана. 6 кыз һәм 1 малай үстерәләр алар. 45 ел бергә үткәргән гомерләрен Җәләлетдин ага зур канәгатьләнү белән искә ала.

—Кияүләрем дә әйбәт, оныкларыбыз да тәртипле. Тормышка шатланып яшисе дә яшисе иде диясе килә.

Солдат үткән юллар һәм еллар гыйбрәтле, тынычлык һәм иминлек телик без аларга.

**Н. ГАФУРОВ.**
Норлат шәһәре.

**УКУЧЫЛАР ИГЪТИБАРЫНА!**

**Бәйрәм көннәре уңаеннан Норлат-Октябрь типографиясе һәм Октябрь район элемтә челтәре тарафыннан газета чыгару графигы үзгәртеләчәк. «Дуслык» газетасының алдагы номерына 1991 елның 13 маенда кул куелачак.**

**МӨХӘРРИР Ә. У. АБДУЛЛИН.**

Учредительләр— халык депутатларының Октябрь район Советы һәм КПССның район партия оешмасы.

РЕДАКЦИЯНЕҢ АДРЕСЫ: 423000, Норлат шәһәре, К. Маркс урамы, 19.
ТЕЛЕФОННАР: мөхәррир—2—12—14, 2—22—81, мөхәррир урынбасары—2—16—44, рус теленә һәм чуваш теленә тәрҗемә буенча мөхәррир урынбасарлары—2—15—63, социаль-экономика бүлеге— 2—22—51, җаваплы секретарь—2—14—16, хатлар бүлеге һәм бухгалтерия—2—18—67.

Газетаны Нурзия ФӘСХЕТДИНОВА җыйды. Рима Ганиева верстка ясады. Клара БОБКОВА басты. Корректор— ЗӨЛФИЯ ВӘЛИЕВА.

«Дуслык» газетасы атнаның сишәмбе, пәнҗешәмбе, шимбә көннәрендә чыга һәм рус, чуваш телләренә тәрҗемә ителә.
Нәшрият, полиграфия һәм китап сәүдәсе буенча ТССР Дәүләт комитетының Октябрьның 50 еллыгы исемендәге Норлат-Октябрь типографиясе.
Күләме—1 басма табак. Заказ 52. Тираж 3411.